АГЕНТСТВО ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**«16» март 2018** № 5

Казан ш.

Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә булган таләпләр һәм аларның ихтыяҗлары буенча килеп туган конфликтларны җайга салу буенча төзелгән Коммиссия хакындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Президентының 2017 елның 19 сентябрендә 431нче номеры белән игълан ителгән “Россия Федерациясе Президенты тарафыннан закончалыкның үтәлешен контрольдә тоту һәм коррупциягә каршы тору буенча кайбер актларга үзгәрешләр кертү турында” Боерыгына һәм Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 11 декабрендә УП-1092нче номеры белән теркәлгән “Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы тору буенча кайбер аерым боерыкларга үзгәрешләр кертү турында” Боерыгына бәйле рәвештә

б о е р а м:

Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә булган таләпләр һәм аларның ихтыяҗлары буенча килеп туган конфликтларны җайга салу буенча төзелгән һәм Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының 15.02.2016 13-2/2лс номеры белән теркәлгән боерыгы белән расланган Коммиссия хакындагы Нигезләмәгә, 3.4.3. пунктларын да өстәп, түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешне кертергә.

“3.4.3 Нигезләмәдәге 3.2., 3.4, 3.4.1 пунктлары буенча каралган дәлилләүче нәтиҗәләр түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

а) Нигезләмәнең 3.1 пунктының “д” пункт астындагы һәм “б” бишенче пункт астыдагы, шулай ук икенче абзацка караган мөрәҗәгатьләр белән белдерүләрдә чагылыш тапкан мәгълүматны;

б) дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка төрле кызыксынуы булган, сораулар һәм үтенечләр белән мөрәҗәгать иткән оешмалардан кергән мәгълүматны;

в) Нигезләмәнең 3.1 пунктының “д” пункт астындагы һәм “б” бишенче пункт астыдагы, шулай ук икенче абзацка караган мөрәҗәгатьләр белән белдерүләрдә чагылыш тапкан, шулай ук 3.13, 3.15.1, 3.18 пунктлары буенча кабул ителергә мөмкин булган карар, тәкъдимнәрне дәлилләүче нәтиҗәләрне, йә булмаса башка төр карарны үз эченә алган нәтиҗәне.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Т.И. Миңнуллина